**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№947**
**12.02.2021**

Башкарма комитетның «Индивидуаль торак фондында, шулай ук турыдан-туры идарә итү ысулы булган йортларда яшәүче гражданнарга йорт кенәгәсеннән өземтә һәм яшәү урыныннан белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 17 июнендәге 2902 номерлы карары үз көчен югалтуны тану хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.20, 5.21 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2020 елның 26 июнендә «Челнинские известия» газетасының 46 нчы санында басылып чыккан «Индивидуаль торак фондында, шулай ук турыдан-туры идарә итү ысулы булган йортларда яшәүче гражданнарга йорт кенәгәсеннән өземтә һәм яшәү урыныннан белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 17 июнендәге 2902 номерлы Башкарма комитет карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов